# ФӘРИТ ЯХИН ПРОЗАСЫНДА ИСЛАМ ФӘЛСӘФӘСЕ

Л.Ф.Җамалиева, Филология һәм
сәнгать институты доценты (КФУ)

Узган гасырның туксанынчы елларында хәбәрдарлык җилләре исә башлагач, Ф.Яхин, беренчеләрдән булып, дини темага яза башлый. Шушы елларда ул “Пәйгамбәрләр тарихы”, “Иман” дип аталган китаплары белән киң җәмәгатьчелеккә таныла. 1994-1998 еллар аралыгында аның өч аерым китап рәвешендә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә багышланган хезмәте язылып басыла, 1999 елда трилогиянең өч китабы бергә “Пәйгамбәребез Мөхәммәд” исеме белән дөнья күрә. 2000 елда галим “Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология” дип аталган бик зур монография бастыра. Әлеге җитди фәнни хезмәт борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбияты ядкәрләре, Ә.Яссәви, С.Бакыргани, К.Сайади, Мәҗлиси, Мөхәммәдьяр һ.б. шагыйрьләр иҗатындагы дини-мистик һәм мифологик символиканы анализлауга багышлана. Галимнең фәнни, фәнни-популяр хезмәтләрендәге дини юнәлеш, билгеле инде аның әдәби иҗатында зур урын ала. 2000 елда басылган “Ак әбиләр догасы” дип аталган җыентыкта шул исем белән бирелгән хикәя бар. Хикәя мең тугыз йөз җитмеш алтынчы елның бик эссе җәен сурәтләүдән башланып китә. Ил өстенә ачлык куркынычы төшә. Корылык һәм ачлык бәласеннән, могҗиза булып, атна буе яңгыр яуса гына котылырга мөмкин. Көннәрнең берендә Дүсем авылы тирәсендәге әүлиялар зираты һәм әүлиялар чишмәсе белән дан тоткан тауда ак әбиләр җыелып Коръән чыга икән дигән хәбәр тарала.

Билгеле, бу атеизм заманы өчен бик сәер, көтелмәгән күренеш була. Мәктәптә “Алла юк!” дип өйрәтсәләр дә, өйдә “Аллаһы әкбәр!” дип, өстәл янында амин тотып үскәнлектән, Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә ышана идек без”- дип сөйли могҗизаны үз күзләре белән күрергә теләгән малай. Актан киенгән, ак яулыклы унбишләп абыстай дүрт көн буе ураза тотып, тау битендә намаз укыйлар, Аллаһыдан яңгыр сорыйлар. “Безнең күңел икегә ярылды. Бер яртысы – денсез, икенчесе әле һаман пакь һәм иманлы хәлендә иде”дип хисләре белән уртаклаша хикәяләүче. Билгеле, корылыктан

интеккән халык, нинди юл белән булса да яңгыр яудырырга тели. “Дәһрилеге белән танылган ата коммунист” Гыйльметдин абзый, могҗиза көтүче балаларның күңеленә коткы сала: намаз укып, ураза тотып кына яңгыр чакырып булса, электән шулай эшләрләр иде. Гарәп чүле күптән гөлбакча булыр иде.” [Яхин, 2000: 4]. Әмма аның вәсвәсәсе акланмый, дүртенче көнне төнлә “туйганчы, тәмам сеңдереп, һәм гөрләвекләр йөгертеп, бөтен дөньяны суга батырып, яңгыр явып үтә”. Игеннәргә корылыктан зыян килсә дә, яңгырның файдасы тия. Алар сакланып калалар.

“Доганың кайчан зыянга булганы бар?” Ак әбиләр күрсәткән могҗизадан соң балаларның да күңелләрендә Аллаһының кодрәтенә ышаныч арта. Шул рәвешчә, Ак әбиләр догасыннан соң булган могҗиза бөтен ил күләмендә дингә каршы агитация алып барылган вакытта да яшүсмер балалар күңелендә иман ныгытырга ярдәм итә.

Язучының икенче бер әсәре – “Әнием, Коръән чыгарсың” повестенда диннең гаилә мөнәсәбәтләрендәге роле күрсәтелә. Бала үзен дөньяга тудырган ата-анасы алдында мәңгелек бурычлы, ата-ана хакын хакламау – иң зур гөнаһларның берсе дигән фикер үткәрелә әсәрдә. Тирә-юньдә танылган бай Корытай Хафизның гаять укымышлы, бик зыялы кызы Шәрифә белән каладан вакытлыча гына ялга кайткан зимагур Хәләф арасында мәхәббәт уты кабынып китә. Һәм данлыклы Тимершаһ хәзрәт Акчуринның улы Дәүләтшаһка ярәшелгән Шәрифә зимагур Хәләф белән өеннән качып китә. Бу хәбәр, билгеле инде, кызларына “мирза кызлары да эсти алмаган белемне һәм тәрбияне биргән” ата-ананы аяктан ега. Хикәяләүче үзе дә кызның бу адымын “дөрестән дә Шәрифәнең бу гамәле юньсезлек иде. Моны кыз үзе генә аңламады” - дип бәяли. Кыздан шактый өлкәнрәк һәм инде дөнья күрергә өлгергән, башлангыч дини белеме булган егет бик зур хата кыла. Беренчедән, ул инде башкага ярәшелгән кызны алып китә. Икенчедән, кыз, Хәләфкә ияреп китәргә теләсә дә, Ислам дине кануннары буенча, егет кызның әти-әнисенә яучы җибәреп, алардан рөхсәт сорап, бөтен дини таләпләрне үтәп өйләнергә тиеш иде. Тирә-юньдәге

муллаларның берсе дә яшьләргә никах укырга теләми. Никах укыган шәкерт икенче көнне үк авылдагы мәдрәсәдән китеп бара. Дини өйрәтмәләр буенча “Никахка әгәр дә биш кеше килмәсә, бу никах туе булмыйча, зина туе булыр. Ул биш кеше болардан гыйбарәт, беренчесе – никах хөтбәсен укучы, икенчесе – вәли, якын карендәше, өченче туганы яки атасы. Шаһитларның икесе дә балигъ булган ир затыннан, мөселман булулары шарт” [Ислам, 1997: 207]. Кызганыч, Хәләф белән Шәрифә никахында, бу таләпләр үтәлми. Шул ук вакытта, мәхәббәте никадәр көчле булмасын, Хәләфнең кызны ул үскән шартларда яшәтерлек мөмкинлеге юк. Кызы хәсрәтеннән Хафиз бай дөнья куя. Җеназага килгән Шәрифә әнисе янында яшәп кала, әтисен җирләгәнгә кырык көн дигәндә кыз бала таба. Фагыйлә түти баланы Хәләфкә күрсәтергә дә теләми хәтта. Кыз ата йортын икенче мәртәбә ташлап чыккач, Фагыйлә түти, кызын каргый: “Шул зимагурың белән рәхәт күрмәсәң иде, ил алдында кадеремне бетердең, арада яхшы булсын дип ничек тәрбияләткән идек, атаң да бәхиллек бирмәде үзеңә... Бу хәлендә үз-үзен онытып, никадәр олуг гөнаһлар кылганлыгын төшенерлек чарасы калмады. ”[Яхин, 2000: 126 ].

Дөрес, кызының кыланмышлары өчен Фагыйлә түтинең җаны сызлавын аңлап була, әмма Ислам дине кануннары буенча каргау – бик зур гөнаһларның берсе. “Ислам дине нигезләре” китабында каргышка түбәндәге адлатма бирелә: “Үзеңә зыян итү яки итмәвенә карамастан, кешегә бәддога уку, аны каргау, явыз дога кылу – болар бар да хәрәм-золым... Чөнки син каргаган бәндә мөселман булып, иманлы икән, ул каргышларың аның өстенә килмәячәк һәм үзеңә әйләнеп кайтачак” [Ислам, 1997:257]. Ана һәм бала мөнәсәбәте хакында әдәби әсәрләрдән, фольклордан бик күп мисаллар китерергә мөмкин. Бу урында татар халык авыз иҗаты мирасындагы “Ана йөрәге” легендасына һәм “Сак-Сок” бәетенә игътибар итү урынлы булыр. Беренчесендә сөеклесен ышандыру хакына анасы йөрәген корбан итүче егет һәм киселгән йөрәкнең телгә килеп, абынып егылган егетне кызгануы турында сүз барса [Риваятьләр, 2000:133], икенчесендә намаз укыганда комачаулаган ике баланың аналары каргышы белән Сак һәм Сокка әверелүе

турында сөйләнә. Әлеге мисаллар ана йөрәгендә мәрхәмәткә, балага мәхәббәткә нинди зур урын булуы хакында сөйли. Шул ук вакытта ана каргышының нинди зур бәхетсезлеккә китерүен күрсәтә

Шәрифәнең йөкле икәнен белгән Фагыйлә, им-томчыдан дару алып кайтып, кызына эчерә башлый. Бу Шәрифәнең үлеменә сәбәпче була. “Моңа кадәр укынган каргышлары кабул булу сәгате тупсадан кереп килә иде инде”. Үлем алдыннан кыз әнисенә соңгы васыятен җиткерә: “Әнием, минем каберем өстендә Коръән чыгарсың!” Бу хәлдән соң акылдан язган Фагыйлә түти кышкы суыкта станса юлында өшеп үлә. Күрәбез, баласын каргаган ананың каргышы үзенә төшә. Шул ук вакытта, кызының баласын төшертәм дип, Фагыйлә түти бик зур гөнаһ кыла – ике җанның үлеменә сәбәпче була – үз кызы һәм туачак оныгы аның кулыннан үлә. “Гөнаһлардан тәмам азат кешеләр дә юк. Шуңа күрә борынгы әүлиялар аклыкка гөнаһ аша, аны үтү аша килгәннәр һәм шушы рәвешле гамәл йөрткәндә генә изгелеккә ирешү мөмкин дип уйлаганнар. Гөнаһның никадәр начар икәнлеген аңлаганнан соң гына сафлыкның бөеклегенә төшенергә мөмкин.” – дип яза автор. [Яхин, 2000: 133]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, Шәрифәнең бәхетсез язмышы аша язучы Ислам фәлсәфәсе буенча, ата-ана хакының олылыгын, ана каргышының, белеп һәм белми кылган гөнаһларның нинди зур фаҗигага китерергә мөмкин икәнлеген күрсәтә. Ислам дине нигезләре буенча зур күләмдәге фәнни-популяр хезмәтләр авторы булган Ф.Яхин бу юнәлешне әдәби иҗатында да уңышлы дәвам иткән. Шуның нәтиҗәсе буларак, Ислам фәлсәфәсенең асылын әдәби сурәтләрдә мавыктыргыч итеп тасвирлаган, укучы күңелендә дини тәгълиматларга хөрмәт уятучы әсәрләр туган.

Әдәбият:

1. Ислам. Белешмә-сүзлек / Төзүче З.Шәфигый. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. -191 б.
2. Яхин Ф. Ак әбиләр догасы // Ак әбиләр догасы: Хикәяләр, повестьлар. – Казан: Татар. кит.нәшр., 255 б. –Б. 4–7.
3. Ислам дине нигезләре. Тупланманы әзерләүче һәм төзүчесе – Ф.Яхин. – Казан: “Раннур” нәшрияты, 1997. – 288 б.
4. Татар халык риваятьләре һәм легендалары. Төзүчесе С.Гыйләҗетдинов. – Казан: “Раннур” нәшрияты, 2000. – 320 б.

**Заявка**

| | |
|---|---|
| ФИО | Замалиева Луиза Фирдусовна |
| Место работы | ИФИ КФУ |
| Факультет, кафедра | Кафедра истории татарской литературы |
| Ученая степень | Кандидат филологических наук |
| Звание, должность | доцент |
| Рабочий телефон | 292-01-30 |
| Домашний телефон | |
| Мобильный телефон | 898-72-61-04-54 |
| Адрес места работы | г. Казань, ул.Татарстана, 2 |
| Домашний адрес | 420056 , г.Казань, ул. Алданскся ,17 |
| E-mail | zamalluiza@mail.ru |
| Научное направление | актульные проблемы тюркской и финно-угорской филологии |